Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлеге составына керүче Мари Тәкәше авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2022 елның 17 декабреннән №7

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлеге Уставының 22 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлеге составына керә торган торак пунктларда гражданнар җыеннарын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 4 октябрендәге 20 номерлы карарына таянып, 2022 елның 17 декабре 13.00 сәг. узган Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлегенең Мари Тәкәше авылында гражданнар җыенының "Сез 2023 елда үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлегенең Мари Тәкәше авылында теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум, 1-2 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, балигъ булмаган балалары булган гаиләләр, көндезге уку формасы студентлары, Россия армиясендә вакытлы хезмәткә чакырылган гражданнар өчен 500 сум күләмендә билгеләргә һәм үзара салым акчаларын Мари Тәкәше авылында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтергә ризамы?"дигән сорау буенча йомгаклау беркетмәсе төзелде Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

- кыш көне юлларны кардан чистарту;
- вак таш сатып алу һәм китерү
- Зиратта павильон төзү өчен төзелеш материаллары сатып алу

Җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 19 граждан кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 19

Ачык тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" 19 граждан тавыш бирде;

"Юк" 0 граждан тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнары җыены КАРАР КЫЛДЫ:

1. Менделеевск муниципаль районының Бәзәкә авыл җирлегенең Мари Тәкәше авылы гражданнар җыенын узган дип танырга, җыен нәтиҗәләре дөрес дип санарга
2. "Сез 2023 елда үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлегенең Сәйтәк авылында теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум, 1-2 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, балигъ булмаган балалары булган гаиләләр, көндезге уку формасы студентлары, Россия армиясендә вакытлы хезмәткә чакырылган гражданнар өчен 500 сум күләмендә билгеләргә һәм үзара салым акчаларын Мари Тәкәше авылында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтергә ризамы?"дигән сорауны танырга.

- Кыш көне юлларны кардан чистарту;
- Зират коймасы өчен төзелеш материалларын сатып алу
- Вак таш сатып алу һәм китерү

3. Әлеге карарны Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында "Бәзәкә авыл җирлеге" бүлегендә - www.mendeleevsk.tatar.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында - pravo.tatarstan.ru урнаштырырга

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
ТР Менделеевск муниципаль районы
Бәзәкә авыл җирлеге башлыгы И.И.Кәшәфетдинов